СОВЕТ
НИЖНЕУРАСПУГИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**02 июль 2025 ел.** Түбән Урысбага **№ 208**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге Федераль закон нигезендә «Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» № 131 – ФЗ, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районының Түбән Урысбага авыл җирлеге Советы КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Түбән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга.:

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын паспортлаштыру.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитетына җирлекнең әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан

Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru һәм шулай ук Түбән Урысбага авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

Түбән Урысбага авыл җирлеге башлыгы,
Совет Рәисе Х.Х.Сибгатуллин.